Республика Татарстан Кукморский муниципальный район Совет Байлянгарского сельского поселения

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл Җирлеге Советы

Байлангар авыл җирлеге Советы

# КАРАР

15 апрель 2025 ел № 8

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 29 сентябрендәге 22 номерлы Байлангар авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча нормалар һәм кагыйдәләр эшләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1042/пр номерлы РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы Боерыгы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Байлангар авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 29 сентябрендәге 22 номерлы Байлангар авыл Җирлеге Совет карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләне керергә:

1.1. V бүлегендәге «Этләрне йөртү мәйданчыклары» бүлекчәсе. Территорияне төзекләндерү элементларына карата таләпләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«167. Хайваннарны йөртү мәйданчыкларын су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зонасының беренче һәм икенче поясыннан читтә паркларда, урман паркларында, гомуми файдаланудагы башка территорияләрдә урнаштырырга кирәк.

Кукмара шәһәре территориясе чикләрендә хайваннарны йөртү рөхсәт ителә торган урыннар Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре администрациясе карары белән билгеләнә.

167.1 Хайваннарны йөртү мәйданчыгы территориясендәге төзекләндерү элементлары исемлегенә түбәндәгеләр керә: өслек, койма, махсус күнекмә җиһазлары, мәйданчыкның эт хуҗалары өчен билгеләнгән өлешендә япма (навес), эскәмияләр, урналар, фекаль салу өчен урналы бер тапкыр кулланыла торган пакетлар әрҗәсе, яктырту җиһазлары, мәгълүмати стенд.

167.2 Хайваннарны өйрәтү мәйданчыкларын төзекләндерү элементлары исемлегенә түбәндәгеләр керә: өслек, койма, махсус күнекмә җайланмалары, шул исәптән өйрәнү, күнекмә, спорт снарядлары һәм корылмалары, яңгырдан саклану өчен япма, инструкторларга ял итү өчен, җиһазларны һәм инвентарьны саклау өчен җылытылган көнкүреш бүлмәсе, эскәмияләр, урналар, фекаль салу өчен урналы бер тапкыр кулланыла торган пакетлар әрҗәсе, яктырту җиһазлары, мәгълүмати стенд.

167.3 Этләр йөртү мәйданчыклары микрорайон һәм торак районның гомуми файдаланудагы яшел үсентеләрдән азат территорияләрендә, метрополитен һәм гомумшәһәр магистральләре линияләренең техник зоналарында, көчәнеше 110 кВт тан артмаган электр тапшыру линияләре астында, су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зонасының беренче һәм икенче поясыннан читтә урнаштырылырга тиеш.

Торак билгеләнешендәге территорияләрдә урнаштырыла торган этләр йөртү мәйданчыклары 400-600 кв. м чикләрендә, башка территорияләрдә – 800 кв. м га кадәр кабул ителә, гамәлдәге төзелеш шартларында, булган территориаль мөмкинлекләрдән чыгып, мәйданчыкларның күләме киметелергә мөмкин.

Мәйданчык чигеннән торак һәм җәмәгать биналарының тәрәзәләренә кадәр ара – кимендә 25 метр, ә балалар учреждениеләре, мәктәпләр, балалар, спорт мәйданчыклары, ял мәйданчыклары участокларына кадәр кимендә 40 метр булырга тиеш.

Мәйданчыкны киртәләү, кагыйдә буларак, биеклеге кимендә 1,5 м булган җиңел металл челтәрдән эшләнә. Киртә элементлары һәм секцияләре, аның аскы кыры һәм җир арасындагы ераклык хайванга мәйданчыктан чыгып китәргә яки үзенә җәрәхәт ясарга мөмкинлек бирмәскә тиеш.

167.4 Хайваннарны йөртү һәм өйрәтү мәйданчыгын хайваннарның очлыкларын имгәтми торган, яхшы дренаж тәэмин итә торган тигез өслекле (газон, ком, ком-туфрак), шулай ук даими рәвештә җыештыру һәм яңарту өчен уңайлы каплама белән каплауны күздә тотарга кирәк.

167.5 Мәйданчыкның хайваннар хуҗалары өчен билгеләнгән өлешен каты яисә катнаш өслек (газонга батырылган плитка һ.б.) белән проектларга кирәк. Мәйданчыкка килү юлы каты өслек белән җиһазландырыла.

167.6 Хайваннарны йөртү һәм өйрәтү мәйданчыгы территориясендә мәйданчыктан файдалану кагыйдәләре урнаштырылган мәгълүмати стенд булдырырга кирәк.

168. Хайваннар йөртү мәйданчыкларын карап тоту эшләренә түбәндәгеләр керә:

а) җәйге һәм кышкы чорда капламны карап тоту, шул исәптән: мәйданчык территориясен чистарту һәм себерү, мәйданчык территориясен юу, мәйданчык территориясенә бозлавыкка каршы хайваннар өчен куркынычсыз чаралар (мәсәлән, ком һәм вак таш бөртекләре) сибү һәм эшкәртү, агымдагы ремонт.

б) хайваннар йөртү мәйданчыгын төзекләндерү элементларын карап тоту, шул исәптән: урналарны чистарту, агымдагы ремонт.»;

1.2. 180-183, 185-200 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.3. 184 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «184. Йорт хайваннарын көтү җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган көтү урыннарында хуҗасы яисә аның кушуы буенча башка зат күзәтүе астында рөхсәт ителә. Хайваннарны җирлек территориясе буйлап көтүлеккә кадәр куып илтү планы җирле үзидарә органының хокукый акты белән раслана».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы: И.Ф.Каримуллин